ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Вөждан ирегe турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 58-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.Р. Зарипов, А.Р. Нәбиева, М.Х. Сәлахов, И.В. Терентьева тарафыннан кертелгән «Вөждан ирегe турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 58-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 28 марты
№ 247-VII ДС

58-7 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
А.Р. Зарипов,
А.Р. Нәбиева,
М.Х. Сәлахов,
И.В. Терентьева
тарафыннан кертелә

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 - 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш); 2024, № 47 (I өлеш), № 93(I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның $1^1$ пунктындагы бишенче абзацта «террорчылыкны финанслауга каршы тору функцияләрен» сүзләрен «террорчылыкны һәм экстремистлык эшчәнлеген финанслауга каршы тору функцияләрен» сүзләренә алмаштырырга;

2) 11 статьяның 3 пунктындагы алтынчы абзацта «террорчылыкны финанслауга каршы тору функцияләрен» сүзләрен «террорчылыкны һәм экстремистлык эшчәнлеген финанслауга каршы тору функцияләрен» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә), һәм террорчылыкны финанслауга каршы көрәш турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 522-ФЗ номерлы Федераль закон белән җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (рәсмиләштерүгә), һәм террорчылыкны финанслауга каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын куллану даирәсенә экстремистлык эшчәнлеген финанслауга каршы тору белән бәйле юнәлеш кертелде, шул исәптән «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законга дини төркем җитәкчеләре (анда катнашучылар) һәм дини оешманы гамәлгә куючылар (анда катнашучылар) өчен чикләүләр һәм тыюлар өлешендә үзгәрешләр кертелә.

Шуңа бәйле рәвештә «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

**«Вөждан ирекге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Вөждан ирекге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына тиешле үзгәрешләр кертүне таләп итми.

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.